Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

26 май 2020 ел. № 62

Территорияне ызанлау проектын
әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планировка структурасы элементларын бүлеп бирү максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы» акционерлык җәмгыятенә инвестиция чаралары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Нефтебаза урамы, 1й., 2 й. адреслары буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар белән чикләнгән территорияне ызанлау проектын эшләүгә керешергә әкъдим итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына (Косарев Д.В.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе турындагы әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Ф. Вәлиев

.

Әлмәт шәһәр Башкарма
комитетының 2020 елның
«26» май № 62 карарына
1 нче кушымта

ГРАНИЦЫ
Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Нефтебаза урамы, 1й., 2 й. адреслары буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар белән чикләнгән территория чикләре




Башкарма комитет җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары
Д.В. Косарев